# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Түбән Юшады торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

22 ноябрь 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Түбән Юшады торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Түбән Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Түбән Юшады торак пунктында Солнечная урамындагы юлны ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Юшады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлеге башлыгы И.Р.Ханов